ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«_18_» _марта_ 2025 ел** **№ _251_**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында вафат булу буенча ведомствоара комиссия турында**

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль законы, 2004 елының 28 июлендәге “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Уставы белән берлектә, һәм мониторинг оештыру, Татарстан Республикасы Арча районы халкының үлү сәбәпләрен өйрәнү һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә үлү очракларын киметүгә юнәлдерелгән нәтиҗәле чараларны үз вакытында күрү максатларында, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Расларга:

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында үлүчеләр саны буенча ведомствоара комиссия составын (килешү буенча) (1нче номерлы кушымта);

- Татарстан Республикасы Арча районында үлүчеләр саны буенча ведомствоара комиссия турында нигезләмәне (2нче номерлы кушымта)

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Э. Ш. Вафинага йөкләргә.

Җитәкче Р.М. Гатиятов

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында үлүчеләр саны буенча ведомствоара комиссия составы**

| | |
|---|---|
| Вафина Э.Ш. | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары - комиссия рәисе; |
| Идрисов Р.И. | “Арча үзәк район хастаханәсе”нең баш табибы - комиссия рәисе урынбасары (килешү буенча); |
| Вафин А.А. | “Арча үзәк район хастаханәсе”нең поликлиника эше буенча баш табиб урынбасары вазыйфаларын башкаручы, комиссия секретаре (килешү буенча); |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Хәбиров А.Ф. | Арча муниципаль районының авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы (килешү буенча); |
| Баһавиев А. | Арча районы буенча ЭЭМ бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Ибраһимова Д.М. | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Арча муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге җитәкчесе (килешү буенча); |
| Бәхтиярова Ф.Р. | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының ЗАГС бүлеге җитәкчесе. |

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында үлүчеләр саны буенча ведомствоара комиссия турында нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында үлем буенча ведомствоара комиссия (алга таба - комиссия) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән төзелә.

1.2. Комиссияне Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары җитәкли.

1.3. Комиссия составына җирле үзидарә органнары вәкилләре, шулай ук килешү буенча хокук саклау органнары, сәламәтлек саклау, социаль яклау учреждениеләре керә. Комиссия әгъзалары үз эшчәнлекләрен иҗтимагый башлангычларда алып баралар һәм аның утырышларында шәхсән катнашалар. Комиссия утырышларына кирәк булганда прокуратура, суд, эшкуарлык структуралары, иҗтимагый оешмалар вәкилләре, авыл җирлекләре башлыклары, Роспотребнадзор белгечләре, медицина белгечләре, статистика бүлеге белгечләре, предприятиеләр җитәкчеләре чакырылырга мөмкин.

## 2. Комиссиянең бурычлары

2.1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында халыкның үлү сәбәпләренә анализ ясау.

2.2. Халыкның үлем санын тотрыкландыруга һәм киметүгә, медицина ярдәменең сыйфатын яхшыртуга һәм оештыруга юнәлдерелгән ашыгыч һәм озак сроклы идарәче карарлар эшләү һәм кабул итү.

## 3. Хокуклар һәм бурычлар

3.1. Комиссия хокуклы:

- ведомство карамагына һәм оештыру-хокукый рәвешләренә карамастан, оешмалар һәм учреждениеләр тарафыннан үтәлүе мәҗбүри булган карарлар чыгарырга;
- комиссия эше өчен җитәкчеләрдән һәм учреждениеләрдән, аларның ведомстводан булуларына һәм оештыру-хокукый рәвешләренә карамастан, кирәкле материаллар һәм мәгълүмат соратып алырга.

3.2. Комиссия бурычлы:

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында халыкның, шул

исәптән хезмәткә сәләтле яшьтәге халыкның үлү күрсәткечләренә динамик анализ ясарга.

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында халыкка медицина ярдәмен оештыруга һәм күрсәтүгә анализ ясарга.

## 4. Комиссия эшен оештыру

4.1. Комиссия утырышлары кирәк булганча, әмма кварталга кимендә 1 тапкыр уздырыла.

4.2. Комиссия утырышы комиссия әгъзаларының гомуми составының кимендә яртысы булганда тулы хокуклы дип санала. Комиссиянең барлык карарлары комиссиянең гомуми составындагы күпчелек тавыш белән кабул ителә.

4.3. Комиссия секретаре комиссия утырышы билгеләнгән датага кимендә 3 көн кала комиссия рәисенә карала торган мәсьәлә нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында үлемгә анализның статистик материалын тапшыра.

4.4. Комиссиянең чираттан тыш утырышы, комиссия рәисенә нигезләнгән тәкъдим белән, комиссия әгъзасы тарафыннан инициатива белән чыгарылырга мөмкин.

4.5. Чираттан тыш утырыш үткәрү турында карар комиссия рәисе тарафыннан кабул ителә.

4.6. Комиссия утырышлары ачык утырышлар рәвешендә дә, ябык утырышлар рәвешендә дә уздырылырга мөмкин. Үткәрү формасы турындагы карар комиссия әгъзаларының гомуми составындагы күпчелек тавыш белән кабул ителә.

4.7. Комиссия утырышлары "Арча үзәк район хастаханәсе" ДАСУдә дә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетында да уздырыла.